**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл жирлегенең Олы Батрас торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар жыены**

**КАРАРЫ**

**23.11.2022** **№ 1**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл жирлеге Олы Батрас торак пунктында гражданнар жыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл жирлегенең Олы Батрас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча һәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Жыелган сумманы жирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:
- стела территориясен төзекләндерү.

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл жирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл жирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

**Жыенда рәислек итүче,**
**жирлек башлыгы** **Т.В. Попова**